**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СТОЛБИЩЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕН
БАШКАРМА КАМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-12-91

**№182** **31.08.2023 г.**

# РЕШЕНИЕ

# КАРАР

**«Җир салымы турында» Столбище авыл җирлеге Советының 18.10.2023 елның 23/1 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль законы, 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Советы карар чыгарды.:

1. Түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 пунктның 1 пунктчасындагы өченче абзацында түбәндәге сүзләрне өстәргә:

- эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш;

1 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы "Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек тармагын үз ихтыяҗлары өчен алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир участоклары

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге - Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Ю.Романова**